# Урта һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары һәм студентлары арасында үткәрелгән “Әдәби табышмак” республика бәйгесе ачу тантанасы



*«Каз канаты» көе, каурыйлар, уенчык казлар*
*Сәхнә. Музыка, 5-6 «каз» чыгып бииләр (ак киемнәр)*

**Ямьсез тавыш.** Хальд, валд, хау, хау.



*Тавышлар, мылтык тавышы, этләр өрә, кызлар йөгерешәләр, уенчык казлар кала, усал бәндә чыгып , аларны җыеп ала, гут-гут, дип алып чыгып китә. Бер каз шушы гаугадан куркып, сәхнә астына төшеп йөгерә. Ялгыз каз тавышы.*

**Каз *(астан менә, сөйли-сөйли, тегендә бара, монда карый)*** Нинди шомлы тынлык! Кыйгак! Кыйгак! Кызлар! Кызлар, дим! Ник дәшмисез? Кыйгак! Кая югалдыгыз? Нишләп берүземне калдырып киттегез? ***(еламсырап, сәхнә алдына утыра, канатлары белән үзен кочып)*** Миңа нишләргә?!

*Маша керә (урак белән эштән кайта, казлар юклыгын күрә, җирдән каурый ала)*



**Маша.** И Ходаем! Казкайларым минем! Бәдбәхетләр!

**Каз.** *(Машага)* Апа жаным! *(барып сарыла)*

**Маша**. Елама, Ала каз, елама! Нишлисең, кешеләр өстенә генә түгел, казлар өстенә дә үләт явы килде. Каһәр суксын ул акай күзле явыз фашистларны! Күр инде, мамык йоннары гына калган минем кошкайларымнан… Эх, эх.. *(сыйпап)* Эле ярый син исән калгансың, Ала каз!

**Каз.** Апа җаным, япа- ялгыз калдым бит! Берүзем!

**Маша**. Алай димә, Ала каз! Әнә, иптәшкә  биш тавыгым…

**Каз.**  Ии, апа җаным,  синең тавыкларың, биләмдә йөреп өйрәнгән  кызыл әтәчкә  ияреләр дә урамга чыгып китәләр ич… Я кеше абзарлары артында йөриләр…

**Маша.**  Ала каз, кәҗәм дә бик акыллы,  булмаса, шуның белән дуслаш!

**Каз.** Акыллысын акыллыдыр да,  әмма аның үзенең ике  бәрәне бар!

**Маша.**  *(аптырап)* Соң, нишләтим соң инде мин сине, Ала каз?  Табигать шулай яраткан: һәр җан иясенең ише бар. Һәр җан иясе ана була, бала үстерә.

**Каз.** Ә мин? Мин бит ялгыз, минем үз ишем юк! Димәк,  мин  бала да чыгара алмыйм… Башкаларның бәхетле яшәүләрен күреп, минем йөрәгем яна. Үземнең шундый аяныч хәлемне  сизгәнгә, эчем поша. *(еламсырый)*

**Маша.** *(тавышын бераз күтәреп)* Җитәр инде, юләр, житәр!  Мә, аша! *(кулыннан ашата)*

*Шул вакытта  Командир һәм 3солдат килеп керә.*



**Командир.** Исәнмесез! Мария Ивановна буласызмы?

**Маша.** *(кулларын сөртеп)* Әйе, мин ул. Сезне кем дип белик?

**Командир.**  Без фронт артыннан ияреп баручы аерым тәэминат ротасы булабыз.   Вакытлыча солдатларны  сезнең өйгә урнаштырабыз, бу приказ.

**Маша.** Әй, рәхмәт яугырлары, үзебезнекеләр икән ич! Узыгыз, уз! Ничә кеше буласыз?

**Командир.** *(кәгазьдән карап)*  Тәк, сезнең өйгә 3 кеше. Менә бу безнең итекче *(кулында ботинкалар, чүкеч һ.б.), итекче  башын гына селки*

**Маша.** Бик яхшы, сезгә чолан булыр.

**Командир**. Бу иптәш безнең  тегүче.

**Маша.** Яхшы, сезне алгы бүлмәгә урнаштырырбыз. Рәхим итегез! *(Иванга)* Ә сез кем буласыз?

**Командир**. *(нидер яза)* Иван, үзең аңлат әле.

**Иван.** Есть аңлатырга! Минем исемем Иван, повар булам! *(ак калфак, ак алъяпкычтан). (Як-ягына каранып)* Иптәш командир, бу кухня кечкенә, әйдәгез бакча артына, ачык җиргә тактадан җәйге кухня ясыйк!

**Командир.** Бик яхшы, иптәш рядовой! Барыгыз, приказны үтәгез!




**Иван.** Есть! *(китә башлый, казны күрә)* Әхи, каз! Исәнмесез, иркәм!

**Каз.** Кыйгак! Миңа сезнең белән барырга ярыймы, иптәш повар?

**Иван.** *(күтәреп карый)* Җиңелсен, иркәм, җиңелсең, яхшылап ашатасы бар үзеңне!

**Каз.** Кый, кый,ког,ког!

**Маша.** Әйдәгез, иптәшләр, тамак ялгап алыгыз булмаса!

*Китәләр. Маша керә.*

**Маша.** Ала каз, ала каз, дим! Деге, деге! Кайда йөрисең, биләмче, кайт! *(алга килеп)* Ии, кайда булсын инде, тагын Иванга ияреп киткәндер. Агылый белән тагылыймыни, иртән ияреп китә шуңа, кич кайта. Көне буе шул кухня тирәсендә. *(көлеп)* Бер этне дә кухняга якын җибәрми. Иван белән дуслашканнан бирле, көрәеп, матураеп китте, бахыр.

*Каз тавышы. Иван керә, Каз*

**Иван.** Маша**,** яңгырда калып, тозым чыланган, бераз тоз бирегез әле, зинһар!



*Маша чыгып китә. Икәүләп, сәхнә алдына утыралар, пычак кайрый*

**Иван.** Мин, Ала каз, элек ресторанда эшләгәндә кош итләреннән иң нәфис, иң затлы ашлар әзерли идем. Әйтик, кыздырылган күркә яки җимеш белән тутырган тавык бик шәп булып чыга иде. Ә менә бу сары аякның ите

инде, узең беләсең, иң мактаулы симез итләрдән санала. Шулай бит, Ала каз? *(пычагын кайрый).*




**Каз.** Шаяртасың?

**Иван.** Курыкма, Ала каз, син минем дустым, мин сине рәнҗетмәм!

*Шул вакытта тавыш (бәбкә тавышы, тавык тавышы), Маша алъяпкыч итәгенә чебиләр салып алып керә, идәнгә тарата*




**Иван.** Тавыгың чеби чыгардымыни, Маша?

**Маша**. Юк, чеби түгел болар.

**Иван.** Кызык…

**Маша.** Безнең басу кырыннан ерак түгел тимер юл станциясе бар. Яз башында бер эшелон колхозчылар фашистлардан азат ителгән авылларына кайтып баралар иде. Үзләре белән мал-туарларын, кош-кортларын да алганнар. Шулардан каз йомыркалары алып калган идем. Кара тавыкны утыртып, бәбкә чыгардым. Каз бәбкәләре ул, каз бәбкәләре!

*Ала каз сикереп тора*

**Ала каз.** Апа җаным, дөрес ишетәмме? Каз бәбкәләре дисеңме?

**Маша.** Әйе, Ала каз, каз бәбкәләре!



**Ала каз.** *(өзгәләнеп)* Апа җаным, кара тавык аларга чын ана була алмас!

**Маша.** Сүзләреңдә хаклык бар, Ала каз. Ул аларны су буена да илтми, рәхәтләнеп йөздерми, чумып уйнарга да өйрәтми.

**Каз.** Әйе-әйе, үлән йолкып ашарга өйрәтәсе урында, җир тибеп, җыен юк-бар нәрсә чүпләргә кыстап маташа!

**Маша.** Булдыксыз ана белән бәбкәләр дә зәгыйфь, аңгыра булып үсәләр. Булмый болай, табигатьнең бу хатасын төзәтергә вакыт җитте! Бар, Ала Каз, җый балаларыңны!

**Иван.** *(кочаклап)* Әй, җан дускаем, семьялы булдыңмыни?!

**Маша.** Менә бит ул, нинди бәхет! Киләсе язга инде үзе йомырка салыр, үзе утырып бала чыгарыр. Миңа байлык, ә аңа бер көтү бәбкәле, тигез бәхетле тормыш килер!





**Гөлназ Фазыловна.** Хәзер исә без торган урамга яңа ямь керде...Аяк тавышлары тына, урам янә көмеш нурлы тынлыкка чума һәм каз тавышлары үтеп китүчене азат ителгән авылда яңадан туып килгән тормышның җанлы сулышы, куанычлы авазы кебек озатып кала.



**Ала каз.** Кайсыгыз белә, бу өзек нинди әсәрдән? *(җаваплардан соң)* Дөрес, Әмирхан Еники “Ялгыз каз”.

**Гөлназ Фазыловна.** Сәхнәдә Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллияте студентлары.

Урта һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары һәм студентлары арасында үткәрелгән “Әдәби табышмак” республика бәйгесен ачып җибәрү өчен, сүз Муса Җәлил

исемендәге Минзәлә педагогия көллияте директоры Хәлиуллина Гөлназ Сәмигулла кызына бирелә.



**Гөлназ Фазыловна.** Гөлназ Самигулловна - жюри рәисе, көчле алкышлар. Калган жюри әгъзалары белән дә танышып үтик:

**Гомәр Филгиз улы Даутов** – Казан Федераль университетының Алабуга институты татар филология кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар Союзы әгъзасы;

**Лилия Альберт кызы Галиева** – Минзәлә шәһәре гимназиясе директоры, филология фәннәре кандидаты;

**Гөлнур Мирзанур кызы Гыйлажетдинова** – бик күп еллар гомерен Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллиятенә багышлаган, югары кваликацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы (лаеклы ялда);

**Илшат Рим улы Вәгыйзов** – АО “Татмедиа”ның “Минзәлә-информ” филиалының җаваплы сәркатибе.

**Гөлназ Фазыловна.** Катнашучылар белән дә танышып үтик:

| *№* | *Уку йорты исеме* | *Команда исеме* |
|---|---|---|
| 1 | ДАҺББУ «Яр Чаллы технология техникумы» | «Алдынгылар» |
| 2 | ДАҺБУ «Актаныш технология техникумы» | «Эрудит» |
| 3 | ДАҺБУ «Казан медицина көллияте» | «Ак чәчәкләр» |
| 4 | ДАҺБУ «Түбән Кама транспорт инфраструктурасы көллияте» | «Хәзинә» |
| 5 | ДАҺБУ «Алабуга политехник көллияте» | «Чулман» |
| 6 | ДАҺБУ «Казан педагогия көллияте» | «Сәмрух» |
| 7 | ДАҺБУ «Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллияте» | «Хуҗалар» |

**Гөлназ Фазыловна.** Программага күз салыйк, эшләү тәртибе белән танышыйк:

| *Үткәрү вакыты* | *Чара* | *Җаваплы* | *Үткәрү урыны* |
|---|---|---|---|
| **8:30-9:30** | Кунакларны каршы алу һәм теркәү | Гыймадиева А.Ф. | колледж фойесы |
| **9:30-10:00** | “Әдәби табышмак” республика бәйгесен ачу тантанасы | Галиева И.М., Талипова Г.Ф., | актлар залы |
| **10:00-10:30** | 1 тур – ***“Бер горурлык хисе яна миндә”*** | Гыймадиева А.Ф., Кәримова А.Ө. | 210нчы кабинет |
| **10:00-10:30** | 2 тур – ***“Кем күбрәк белә?”*** | Талипова Г.Ф. | 106нчы кабинет |
| **10:00-10:30** | 3 тур – ***“Башваткыч”*** | Шәйсуварова Л.Х., Гыйлаҗетдинов И.И. | 105нче кабинет |
| **10:40-11:10** | 4 тур –***“Бердәмлектә – көч”*** | Талипова Г.Ф. | актлар залы |
| **11:20-12:00** | 5 тур – ***“Талантыңа җилкән тек”*** | Талипова Г.Ф. | актлар залы |
| **12:00-12:30** | Төшке аш | Никитина Р.Д., Зиннурова Л.Б. | ашханә |
| **12:00-12:30** | Музейга экскурсия | Данилова Э.И. | музей |
| **12:30-13:00** | Бәйгене ябу тантанасы Җиңүчеләрне бүләкләү | Талипова Г.Ф., Галиева И.М. | актлар залы |

**Гөлназ Фазыловна**. Барыбызга да уңышлар!

**1 тур - “Бер горурлык хисе яна миндә”**

***1. «Ает» – бу нәрсә атамасы?***

А) шигырь

**Б) авыл**

В) газета

***2. “Ярлы Кәрим” – бу кем?***

А) Ф.Кәримнең әтисенең кушаматы

**Б) Ф.Кәримнең абыйсының псевдонимы**

В) Ф.Кәримнең псевдонимы

***3. Казан төзелеш техникумы Фатих Кәримнең биографиясе белән ничек бәйләнгән?***

**А) Ф. Кәрим анда укыган**

Б) Ф.Кәрим анда эшләгән

В) Ике җавап та дөрес

***4. Ф. Кәримнең ин беренче эшләгән газетаның исеме***

А) «Крестиян гәзите»

**Б) «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»)**

В) «Кызылармияче»

***5. Әлеге шигырьнең кайсысы Ф. Кәрим иҗатына керми? (артык җавапны тап)***

А) «Аучылар»

Б) «Аникин»

**В) «Сүз»**

***6. 1938нче елның 3нче гыйнвары Ф.Кәримнең тормышында нинди вакыйга була?***

**А) Кулга алына**

Б) тәүге җыентыгы дөнья күрә

В) язучылар берлегенә кабул ителә

***7. «Пантөрекче, «Милләтче», «Буржуазия ялчысы» - болар нинди атамалар?***

А) Ф.Кәримнең 1938нче елга кадәр чыккан шигырьләренең исеме

**Б) Ф.Кәримне ирегеннән мәхрүм итүдәге гаепләү билгеләмәләре**

В) Ф.Кәримнең 1939нчы елда чыккан поэмаларының атамасы

***8. Ф. Кәрим Бөек Ватан сугышында нинди хәрби званиядә була?***

А) Рядовой, кече офицер

Б) Кече офицер, взвод командиры

**В) Барлык җаваплар да дөрес**

***9. Ф.Кәримнең сугыш чоры иҗатына хас тематика***

А) Гади сугышчыларның батырлыгы, эчке кичерешләре

Б) Гаиләсенә, туганнарына, туган иленә мәхәббәте

**В) Ике җавап та дөрес**

***10. Ф.Кәримнең драма әсәрен билгелә***

**А) «Шакир Шигаев»**

Б) «Разведчик язмалары»

В) «Язгы төндә»

***11. Ф. Кәрим шигъриятендә гармун зур урын алып тора. Кайсы шигырендә гармун образы юк?***

А) «Окоп җыры»

Б) «Кыңгыраулы яшел гармун»

**В) Дөрес җавап юк**

***12. Ф. Кәримнең балалар өчен язылган әсәре***

**А) «Аучы»**

Б) «Тимер һәм тимерче»

В) «Кыңгыраулы яшел гармун»

***13. «Утырдым яшел вагонга***

***Карыйм тәрәзәсеннән,***

***Шат, бәхетле киләчәгем,***

***Күгәрченем, гөл чәчәгем,***

**……………………………………..**

***Шигырьнең соңгы юлын тап***

А) Сине кочаклап үбәм

Б) Тиздән кайтырмын өйгә

**В) Хатлар көтәрмен синнән**

***14. Бу өзек Ф. Кәримнең кайсы шигырьләреннән алынган?***

***Синен өчен, шушы балам өчен,***

***Нәселем өчен, Туган ил өчен.***

***Мылтык тотып баскан җиремнән***

***Бер адым да артка чигенмәм.***

А) «Пионерка Гөлчәчәккә хат»

**Б) «Ант»**

В) «Үлем уены»

***15. «Илең турында уйласаң, гомерең озын була» дигән юллар кайсы шигырьдән?***

**А) «Сөйләр сүзләр бик куп алар»**


Б) «Ватаным өчен»

В) «Ант»

**<u>2 тур - “Кем күбрәк белә?”</u>**

**Галиәсгар Камалның “Банкрот” һәм “Беренче театр” әсәрләренә караган катнашучыларны, җөмләләрне табарга:**

| | | |
|---|---|---|
| Хәмзә бай | Факиһә | Гөлҗиһан |
| Гафифә | Биби | Хәдичә |
| Вәли | Фатыйх | Гарәфи |
| Хәбибрахман | Сиражетдин | Хәмди |
| | | Мәрфуга |
| | | Нәгыймә |
| | | Камали |
| | | Ногман |
| | | Әхмәт |
| | | Себер бае |




- Ә, кара әле, хәтеремдә дә юк икән, намазлык дигәч, исемә төште, анда сиңа ничә пар күлмәк кирәк булыр?
- Байлык, шатлык белән көн күрергә, шатлык, рәхәтлек белән йөреп кайтырга насыйп булсын.
- Минем бу сөйләгән сүзләремне син тагы кодагыйларга барып әйтәкүрмә, алар усаллыкны беткәнче белә торган явыз, начар кешеләр.
- Бар икән кылану, ансы да ярамый, монсы да ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр.
- Унбиш тиен дә, унбиш тиен, утыз тиен; тагын унбиш тиен, була кырык биш тиен.
- Алары да шул кибетчеләр яклы, аларга кибетчеләр яклы булмыйча ярыймы соң, кибетчеләр бит аларга унар, унбишәр тиенләп яудыралар.
- Көне буе байга килгән бер кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да күрә!

- Шул, менә мине бер айдан бирле инде акча сорап йөдәтәләр, “бирмәсәң, чыкмыйбыз” диләр.
- Аңгыра,  без сезнең шикелле кош тотарга йөрүчеләрнең үзләрен дә яхшы гына капкынга эләктерәбез.
- Бөтен яктан урыннарым белән әллә кайда, түбәнгә таба, җир астына, караңгыга төшеп киткән шикелле булам.

**3 тур - “Башваткыч”**

Н. Исәнбәт




**1. Н. Исәнбәтнең әхлакый-этик мәсьәләләрне яктырткан психологик драмасы.**



**2. Н. Исәнбәткә 3 томлык “Татар халык мәкальләре” җыентыгы өчен бирелгән премия.**

**3. 1930 нчы елда Н. Исәнбәтне милләтчелектә гаепләп кулга алалар. “Милләтче” оешманың атамасы.**

**4. Н. Исәнбәтнең беренче татар профессиональ актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина- Волжская турындагы драмасы.**

**5. Н. Исәнбәт 1956 нчы елда беренче булып бу каһарманга һәм аның көрәштәшләренә багышлап әсәр яза. Каһарманның исем-фамилиясе.**

**6. Н. Исәнбәтнең тулы исеме.**

**7. Н. Исәнбәт туган авыл.**

**8. 1930 нчы елларда язучылык эшеннән читләштерелгән Н. Исәнбәт шушы фабрикада гади эшче булып эшли. Аның бу исемдәге трагедиясе дә бар.**

**9. Балалар өчен язылган “... батыр маҗаралары” әкият-поэмасы.**

**10. Балалар өчен язылган әкият-пьеса исеменең беренче сүзе.**

**11. Н. Исәнбәт тарафыннан тәрҗемә ителгән А.С. Пушкин әсәре.**

**12. Н. Исәнбәтнең Алтын Урда ханлыгы тарихы чоры белән бәйле әсәре.**

**13. Н. Исәнбәтнең фамилиясе.**

**14. Уфада Н. Исәнбәт белем алган мәдрәсә.**

**15. Н. Исәнбәтне драматург буларак таныткан комедия.**

**<u>4 тур –“Бердәмлектә – көч”</u>**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәби балалары, оныклары кайтуына нәрсәләр әзерли?**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Суфиян ни өчен Саратовка еш йөри?**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәбинең нинди мал-туары бар?**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәби улы Суфиянга нинди ядкарен калдырырга тели?**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Сәлимҗан кем ул?**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәренең төп герое Акъәбинең ничә баласы бар һәм алар кайда яшиләр?**

**Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәбине алырга кайтканда Гөлбикә энисенә күчтәнәчкәниләр алып кайта?**

**Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә вакыйгаларны хикәяләүче шәкерт, бөтен дөнья ишетерлек итеп, нәрсә дип кычкырырга тели?**

**Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә Бәдретдин энисенә багышлап нинди көй уйный?**

**Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә Бәдретдин нинди акча эшләү юллары тапкан?**

**Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә сабагы дүрт кырлы, озын гына бер үсемлекне автор авылында “тәмлекәй” дип йөртәләр, ди. Башкортларда ул үсемлекне ничек атыйлар? (Бәдретдин әйтә)**

**Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә шәкертләрне Бәдретдиннең энисе нинди аш белән сыйлый?**

1. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәби балалары, оныклары кайтуына нәрсәләр әзерли?** (маен-күкәен җыя, итен-казылыгын каклый, шомырт, эремчек, корт, киптерә)

2. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Суфиян ни өчен Саратовка еш йөри?** (хатынының туганнарына кунакка бара)

3. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәбинең нинди мал-туары бар?** (кәҗә, тавык-чебеш, казлар)

4. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәби улы Суфиянга нинди ядкарен калдырырга тели?** (картыннан калган камчат бүреген)



5. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Сәлимҗан кем ул?** (Акъәбинең ире, балаларының әтисе)

6. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә Акъәбине алырга кайтканда Гөлбикә әнисенә күчтәнәчкә ниләр алып кайта?** (берничә лимон һәм 1 кап шоколад кәнфит)

7. **Әмирхан Еникиның “Әйтелмәгән васыять” әсәренең төп герое Акъәбинең ничә баласы бар һәм алар кайда яшиләр?** (4. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә, кемдер булып эшли).



8. **Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә вакыйгаларны хикәяләүче шәкерт, бөтен дөнья ишетерлек итеп, нәрсә дип кычкырырга тели?** (“Матур, матур бит ул Бәдретдиннең әнисе!”)

9. **Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә Бәдретдин әнисенә багышлап нинди көй уйный?** (“Салкын чишмә”)



10. **Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә Бәдретдин нинди акча эшләү юллары тапкан?** (начар укучыларның дәресләрен хәзерләшкән өчен аңа аз-маз тама иде, хәлфәләргә дә булышкалый

иде, аннары авыру-сырхауларга догалыклар, аятелкөрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде)

11. **Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә сабагы дүрт кырлы, озын гына бер үсемлекне автор авылында “тәмлекәй” дип йөртәләр, ди. Башкортларда ул үсемлекне ничек атыйлар? (Бәдретдин әйтә)** (“кияү камчысы” дип, чөнки очындагы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул чынлап та чуклы камчыга охшап китә)

12. **Әмирхан Еникиның “Матурлык” әсәрендә шәкертләрне Бәдретдиннең әнисе нинди аш белән сыйлый?** (аш белән түгел, өстәлдә ярты ипи, тустаган белән сөт, өчаяк белән йомырка тәбәсе)

## 5 тур – “Талантыңа җилкән тек”



**1.«Чулман» командасы**

**ДАҺБУ «Алабуга политехник көллияте»**



**2.«Эрудит» командасы**

**ДАҺБУ «Актаныш технология техникумы»**





**3. «Сәмрух» командасы ДАҺБУ «Казан педагогия көллияте»**



**4. «Ак чәчәкләр»**

**командасы «ДАҺБУ «Казан медицина көллияте»**

**5. «Хәзинә» командасы ДАҺБУ «Түбән Кама транспорт инфраструктурасы көллияте»**





**6. “Алдынгылар” командасы**

**ДАҺББУ «Яр Чаллы технология техникумы»**



**7. “Хуҗалар” командасы**

**ДАҺБУ «Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллияте»**


ДИПЛОМ
РӘХМӘТ ХАТЫ


ДИПЛОМ
РӘХМӘТ ХАТЫ

КӨН ТЕМАСЫ

# Минзәлә педагогия көллиятендә «Әдәби табышмак» республика бәйгесе узды

Ильшат Вагизов, 13 декабрь 2024 - 15:08

52 0 0

**Татарстанның төрле почмакларыннан килгән катнашучыларның һәркайсы призер булды**





Илшат Вагыйзов, «Минзәлә-информ»

Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллиятендә урта һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары һәм студентлары арасында «Әдәби табышмак» республика бәйгесе узды. Конкурс "Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү«дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелде.

Бәйге башланыр алдыннан килгән кунакларны, катнашучыларны Минзәлә педагогия көллияте директоры Гөлназ Хәлиуллина сәламләде, ә уку йортының талантлы студентлары Әмирхан Еникинең «Ялгыз каз» әсәрен (сценарийны адаптацияләде һәм куйды – Илфания Галиева) сәхнәләштерделәр.

Конкурс барлыгы 5 турдан торды. 4 есе танылган татар язучылары Фатих Кәрим, Нәкый Исәнбәт, Галиәскәр Камал, Әмирхан Еники иҗатына багышланган иде. Ә соңгы, 5 нче турда, командалар Гаилә елы тематикасы буенча үзләренең сәхнә осталыкларын тәкъдим иттеләр.

Барлык биремнәрне үтәп чыкканнан соң урыннар түбәндәгечә билгеләнде: «Хуҗалар» (Минзәлә педагогия көллияте), «Алдынгылар» (Яр Чаллы технология техникумы) — 1 урын, «Эрудит» (Актаныш технология техникумы), «Сәмрух» (Казан педагогия көллияте) — 2 урын, «Ак чәчәкләр» (Казан медицина көллияте), «Хәзинә» (Түбән Кама транспорт инфраструктурасы көллияте), «Чулман» (Алабуга политехник көллияте) — 3 урын яуладылар. Аларның һәркайсына дипломнар һәм акчалата премияләр тапшырылды.

Шулай ук бәйгене оештыруда һәм актив катнашканнары өчен жюри әгъзалары, педагогия көллияте укытучылары Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының Рәхмәт хатлары белән билгеләп үтелде. Форсаттан файдаланып, жюри әгъзасы — филолгия фәннәре докторы, КФУ Алабуга институты татар филологиясе кафедрасы доценты Гомәр Даутов бәйгегә килгән студентларын кыскача гына үз уку йортлары белән дә таныштырды.

Бәйгегә килүчеләргә уку йортының ашханәсендә ашату оештырылды, шулай ук һәркем педагогия көллиятендәге Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең музее белән таныша алды.

акцент
«Әдәби табышмак» — нигезләмә буенча укучылары белән бергә укытучылары да катнаша торган республикада үткәрелүче бердәнбер бәйге. Минзәлә педагогия көллияте данын татар теле һәм әдәбияты укытучысы Илгизә Хәйруллина һәм студентлар Диләрә Сабирова, Ралина Минһаҗева яклыдылар. Бәйгене Минзәлә педагогика көллиятенең милли мәгариф бүлеге мөдире Гөлназ Талипова алып барды.